**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 14 июль № 477

г. Казань

Ведомствоара эшче төркем
төзү турында

Гражданнарның аерым категорияләрен дарулар белән тәэмин итү өлешендә социаль хезмәтләр җыелмасы белән тәэмин итү эшен оештыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Гражданнарның аерым категорияләрен дарулар белән тәэмин итү өлешендә социаль хезмәтләр җыелмасы белән тәэмин итүгә юнәлдерелгән чараларны оештыру һәм үткәрү буенча ведомствоара эшче төркем төзергә.

2. Гражданнарның аерым категорияләрен дарулар белән тәэмин итү өлешендә социаль хезмәтләр җыелмасы белән тәэмин итүгә юнәлдерелгән чараларны оештыру һәм үткәрү буенча ведомствоара эшче төркем турында нигезләмәне һәм аның составын расларга (теркәлгәннәр).

3. Гражданнарның аерым категорияләрен дарулар белән тәэмин итү өлешендә социаль хезмәтләр җыелмасы белән тәэмин итүгә юнәлдерелгән чараларны оештыру һәм үткәрү буенча ведомствоара эшче төркемгә дарулар белән тәэмин итү өлешендә социаль хезмәтләр җыелмасын саклау турында Татарстан Республикасы халкы арасында аңлату эшләре үткәрүне оештырырга.

4. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башлыкларына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә дарулар белән тәэмин итү өлешендә социаль хезмәтләр җыелмасын саклау турында Татарстан Республикасы халкы арасында аңлату эшләре үткәрү буенча ведомствоара эшче төркемнәр төзергә;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгели торган вакытларда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына мәгълүмат тапшырып, гражданнарның аерым категорияләрен дарулар белән тәэмин итү өлешендә социаль хезмәтләр җыелмасы белән тәэмин итүгә мониторинг үткәрергә.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 ел, 17 август, 1025-б, 2015 ел, 3 июль, 1429-б боерыклары үз көчен югалтуын танырга.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 14 июль, 477 нче карары белән расланды

Гражданнарның аерым категорияләрен дарулар белән тәэмин итү өлешендә социаль хезмәтләр җыелмасы белән тәэмин итүгә юнәлдерелгән чараларны оештыру һәм үткәрү буенча ведомствоара эшче төркем турында
нигезләмә

1. Гражданнарның аерым категорияләрен дарулар белән тәэмин итү өлешендә социаль хезмәтләр җыелмасы белән тәэмин итүгә юнәлдерелгән чараларны оештыру һәм үткәрү буенча ведомствоара эшче төркем (алга таба – эшче төркем) дәүләт хакимияте органнары, медицина оешмалары, массакүләм мәгълүмат чаралары, иҗтимагый оешмаларның килешенгән гамәлләрен тәэмин итү максатларында оешты.

2. Эшче төркем Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән оештырыла һәм таратыла.

3. Эшче төркем үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

4. Эшче төркемнең төп бурычлары түбәндәгеләр:

гражданнарның аерым категорияләрен дарулар белән тәэмин итү өлешендә социаль хезмәтләр җыелмасы белән тәэмин итү буенча халык арасында аңлату эшләре үткәрүне оештыру;

дарулар белән тәэмин итү өлешендә социаль хезмәтләр җыелмасыннан баш тарткан гражданнар саны мониторингын үткәрү;

гражданнарның аерым категорияләрен социаль хезмәтләр җыелмасы белән тәэмин итүгә юнәлгән чараларны оештыру мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре белән республика селектор киңәшмәләре үткәрүне оештыру.

5. Эшче төркем үзенә йөкләнгән бурычларын үтәү өчен дәүләт хакимияте органнарыннан, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарыннан һәм оешмалардан үз компетенциясенә керә торган мәсьәләләр буенча законнарда билгеләнгән тәртиптә материаллар һәм мәгълүмат соратырга хокуклы.

6. Эшче төркемгә йөкләнгән бурычларны үтәүне оештыруны, шул исәптән эшче төркем утырышын үткәрү турында карарлар кабул итүне эшче төркем рәисе гамәлгә ашыра.

7. Эшче төркем утырышлары кирәк булган саен үткәрелә.

8. Эшче төркем карарлары эшче төркем рәисе раслый торган беркетмә белән рәсмиләштерелә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 14 июль, 477 нче карары белән расланды

## Гражданнарның аерым категорияләрен дарулар белән тәэмин итү өлешендә социаль хезмәтләр җыелмасы белән тәэмин итүгә юнәлдерелгән чараларны оештыру һәм үткәрү буенча ведомствоара эшче төркем составы

| | |
|---|---|
| Шәйхразиев Васил Габтелгаяз улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, эшче төркем рәисе |
| Вафин Адел Юныс улы | Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры, эшче төркем рәисе урынбасары |

Эшче төркем әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Абдреева Юлия Ивановна | Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры урынбасары |
| Әхмәтова Эльвира Фәнис кызы | Республика «Татмедиа» бама һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесенең беренче урынбасары |
| Бәдриев Илдар Фоат улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Социаль үсеш идарәсе башлыгы |
| Вәлиуллина Асия Зиннәт кызы | Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге идарәчесе урынбасары (килешү буенча) |
| Пузанова Ольга Вениаминовна | Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча медик-социаль экспертиза баш бюросы» федераль казна учреждениесе җитәкчесенең эксперт эше буенча урынбасары (килешү буенча) |
| Шакирова Гүзәл Рәис кызы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсе башлыгы |
| Шакиров Минсәгыйть Закир улы | Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы рәисе (килешү буенча) |
| Яркәева Фәридә Фатыйх кызы | Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры урынбасары. |

---